| СОВЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|---|
| **РЕШЕНИЕ**<br>**14.11.2016** | Зеленодольск шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 148** |

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 9 ае эчендә тотылган резерв фонды акчаларын тоту турында

«Зеленодольск муниципаль районы финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесе җитәкчесе О. П. Дёгтеваның Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның тугыз ае эчендә тотылган резерв фондының акчаларын тоту турындагы мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 81 статьясына, 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына, Зеленодольск муниципаль районында бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә таянып, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 9 ае эчендә тотылган резерв фонды акчаларын тоту турында мәгълүматны игътибарга алырга (кушымта итеп бирелә).
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә урнаштырырга.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы,**
**Совет рәисе** **А. В. Тыгин**

Зеленодольск муниципаль районы Советы
2016 елның 14 ноябрендәге
148 номерлы карарына
кушымта

***Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 1 октябренә резерв фонды акчаларын тоту турында мәгълүмат***

| *№ п/п* | *Түләүне билгеләү* | *Сумма (сум)* |
|---|---|---|
| 1 | Янгыннан зыян күрүчеләргә матди ярдәм күрсәтү | 346 185,00 |
| 2 | Дәвалану өчен матди ярдәм күрсәтү | 50 000,00 |
| 3 | “Үлем белән бәйле рәвештә” матди ярдәм күрсәтү | 30 000,00 |
| 4 | Матди ярдәмнең башка төрләрен күрсәтү | 157 500,00 |
| 5 | «Сабантуй-2016» татар милли бәйрәмен үткәрү | 1 176 180,22 |
| 6 | Крещение бәйрәме көннәрендә юлларны җыештыруга, шул исәптән: “Раифа авыл җирлеге” - 43 200 (Кырык өч мең ике йөз) сум, “Әйшә авыл җирлеге” МБ - 39 999 (Утыз тугыз мең тугыз йөз туксан тугыз) сум 99 тиен. | 83 199,99 |
| 7 | Административ комиссия эшчәнлегенә бәйле почта чыгымнарын түләү өчен | 50 000,00 |
| 8 | Зеленодольск шәһәре, Сәйдәшев урамы, 15 йорт адресы буенча лифт һәм фасадның тышкы бизәлешенә ремонт-төзекләндерү эшләрен түләү өчен | 583 783,67 |
| 9 | «Гари поселогы» ТИҮнә Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 71 еллыгына багышланган чаралар әзерләү һәм уздыру өчен матди ярдәм күрсәтү (Җиңү скверы төзелешен һәм җиһазларын тәмамлау) | 100 000,00 |
| 10 | Транспорт хезмәтләреннән бертигез файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә "Экспресс" ҖЧҖ субсидиясе | 1 000,00 |
| 11 | Зеленодольск шәһәренең вәкиллекле органы депутатлары өстәмә сайлауларны уздыру | 41 776,00 |
| 12 | Комаров урамы, 15 йорт, 17 йорт буенча ГВС челтәрләрендә аварияне бетерү өчен материаллар сатып алу | 257 826,70 |
| 13 | "ТР Зеленодольск муниципаль районының мактаулы гражданы", "ТР ЗМР алдындагы казанышлары өчен" исемнәре өчен бер тапкыр түләнә торган акчалата премия | 223 000,00 |
| 14 | Зеленодольск шәһәрендәге урам-юл челтәрен кардан чистартуга "Буран" ОП режимын өлешчә кертү сәбәпле, «Коммуналь хуҗалык» МУП чыгымнарын компенсацияләү өчен (билгеләнгән урыннарда кар чыгаруны һәм складлауны да кертеп) | 999 657,86 |
| 15 | 2016 елгы уңышны җыюда ЗМР авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә алдынгы комбайнчыларны бүләкләү өчен | 105 462,00 |
| 16 | Мактаулы гражданнар үлеменә бәйле рәвештә матди ярдәм күрсәтү | 25 000,00 |
| | ***БАРЛЫГЫ*** | ***4 230 571,44*** |